Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Габдрахман авыл Советы
КАРАРЫ

11 декабрь 2020 ел №10

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советының 2009 елның 25 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советы Регламенты турында" 90 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының "Габдрахман авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 29 статьясы нигезендә, Әлмәт шәһәре прокуратурасының 21.07.2020 ел, № 02-01-25/2020 таләбен карап

Габдрахман авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советының 2009 елның 25 декабрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советы Регламенты турында» 90 нчы номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советының 21.04.2014 ел, 72 нче номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 15 статьяның 2 пунктында «кагыйдә буларак» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 31 статьяның 2 пунктында «кире кайтарылырга мөмкин» сүзләрен «кире кайтарыла» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Габдрахман авылы, Совет урамы, 77 йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән вакыттан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Габдрахман авыл җирлеге Башлыгына йөкләргә.

Габдрахман
авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш.Мотаһиров